**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 28 март № 197

г. Казань

Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затларга мәгариф һәм фән өлкәсендә чаралар (конференцияләр, киңәшмәләр, олимпиадалар, симпозиумнар, съездлар, белем бирү сменалары, күргәзмәләр, конкурслар, һөнәри осталык чемпионатлары, шулай ук бүтән чаралар) оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә (кире кайтаруга) субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә һәм юридик затларга мәгариф һәм фән өлкәсендә чаралар (конференцияләр, киңәшмәләр, олимпиадалар, симпозиумнар, съездлар, белем бирү сменалары, күргәзмәләр, конкурслар, һөнәри осталык чемпионатлары, шулай ук бүтән чаралар) оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (кире кайтару) максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затларга мәгариф һәм фән өлкәсендә чаралар (конференцияләр, киңәшмәләр, олимпиадалар, симпозиумнар, съездлар, белем бирү сменалары, күргәзмәләр, конкурслар, һөнәри осталык чемпионатлары, шулай ук бүтән чаралар) оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә (кире кайтаруга) субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\197.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 28 март, 197 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затларга мәгариф һәм фән өлкәсендә чаралар (конференцияләр, киңәшмәләр, олимпиадалар, симпозиумнар, съездлар, белем бирү сменалары, күргәзмәләр, конкурслар, һөнәри осталык чемпионатлары, шулай ук бүтән чаралар) оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә (кире кайтаруга) субсидияләр бирү
тәртибе

1. Бу Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затларга мәгариф һәм фән өлкәсендә чаралар (конференцияләр, киңәшмәләр, олимпиадалар, симпозиумнар, съездлар, белем бирү сменалары, күргәзмәләр, конкурслар, һөнәри осталык чемпионатлары, шулай ук бүтән чаралар) оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә (кире кайтаруга) субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр юридик затларга мәгариф һәм фән өлкәсендә чаралар (конференцияләр, киңәшмәләр, олимпиадалар, симпозиумнар, съездлар, белем бирү сменалары, күргәзмәләр, конкурслар, һөнәри осталык чемпионатлары, шулай ук бүтән чаралар) (алга таба – чаралар) оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (кире кайтару) максатларында бирелә.

3. Субсидия бирүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы бюджет акчасы белән төп идарәче булып Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тора (алга таба – вәкаләтле орган).

4. Субсидияләр юридик затларга әлеге Тәртипнең 2 пунктында каралган максатларга вәкаләтле органга тиешле финанс елына расланган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары кысаларында бирелә.

5. Субсидияләр оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән тыш) түбәндәге шартларга җавап бирә торган юридик затларга бирелә:

чаралар оештыруны һәм үткәрүне гамәлгә ашыра;

билгеләнгән тәртиптә теркәлгәннәр һәм үз эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыралар;

субсидия бирү турында килешү төзү планлаштырылган айга кадәрге айның беренче көненә:

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм бүтән мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә түләү вакыты җиткән бурычлары юк;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән бүтән хокукый актлар нигезендә бирелгән, Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына кайтару буенча вакыты чыккан бурычы һәм Россия Федерациясе бюджет

системасының тиешле бюджеты каршында бүтән вакыты чыккан бурычы юк;

үзгәртеп төзү, бетерү яки банкротлык стадиясендә түгел һәм хуҗалык эшчәнлеге алып баруга чикләүләре юк;

чит ил юридик затлары, шулай ук устав (җыелма) капиталларында теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән салым салуның ташламалы салым режимы һәм (яки) финанс операцияләре үткәргәндә мондый юридик затларга мөнәсәбәттә мәгълүматны ачу яки бирү күздә тотылмаган дәүләт яки территория (офшор зоналар) булган чит ил юридик затлары өлеше гомумән алганда 50 проценттан артып киткән россия юридик затлары түгел;

әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга бүтән норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар нигезендә Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан акча алмаган.

6. Субсидия алу өчен юридик затлар вәкаләтле органга түбәндәге документларны тапшыра:

вәкаләтле орган билгеләгән форма буенча, исәпләүләр һәм чыгымнарны нигезләү турында документлары белән субсидия бирү турында заявка (алга таба – заявка);

юридик затны гамәлгә кую документлары, шулай ук аларга кертелгән барлык үзгәрешләр турында документлар күчермәләре;

юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе;

салымнар, җыемнар түләү һәм Россия Федерациясе бюджет системасының бюджетларына бүтән мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар юклыгын раслый торган документлар;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән бүтән хокукый актлар нигезендә бирелгән, Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына кайтару буенча вакыты чыккан бурычы һәм Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджеты каршында бүтән вакыты чыккан бурычы юклыкны раслый торган документлар;

юридик зат үзгәртеп төзү, бетерү яки банкротлык стадиясендә түгел һәм хуҗалык эшчәнлеге алып баруга чикләүләре юклыкны раслый торган документлар;

оешма әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга бүтән норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар нигезендә Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан акча алмаганлыкны раслый торган документлар;

чараны оештыру һәм үткәрү белән бәйле гамәлдә тотылган чыгымнарны раслый торган документлар (күрсәтелгән чыгымнарны кайтаруга субсидия бирелгән очракта):

чараны оештыру һәм үткәрүгә чыгымнар сметасы;

калькуляция, меню (исәпләүләрне теркәп һәм бәяләрен нигезләп);

шартнамәләр, әлеге шартнамәләрне үтәү турында беренчел документлар;

Россия Банкының «Саф акчаларны гамәлгә ашыру турында» 2013 ел, 7 октябрь, 3073-У номерлы күрсәтмәләрен исәпкә алып рәсмиләштерелгән түләү документлары

(счетлар, счет-фактуралар, товар-транспорт документлары, түләү кәгазьләре, керем һәм чыгым ордерлары);

проект-смета документлары, № КС-2 формасы буенча эшләнгән эшләрне кабул итү актлары һәм № КС-3 формасы буенча башкарылган эшләр һәм чыгымнар бәясе турында белешмәләр.

7. Заявкалар кабул итү башлану һәм тәмамлану вакытлары, заявкаларны карап тикшерү графигы вәкаләтле орган боерыгы белән раслана. Әлеге мәгълүмат заявкалар кабул итү башланганчы эш көннәрендә исәпләнгән 10 көн эчендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә вәкаләтле органның рәсми сайтында урнаштырыла.

8. Вәкаләтле орган теркәлгән документлары белән заявкаларны кабул итә һәм алар кергән көннән соң бер көн эчендә терки.

9. Заявка теркәлгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән 20 көн эчендә вәкаләтле орган аны карап тикшерә һәм субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту турында боерык рәвешендә карар кабул итә.

10. Субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр түбәндәгеләр:

әлеге Тәртипнең 6 пунктында каралган документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

юридик затның әлеге Тәртипнең 5 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

юридик зат тапшырган заявкадагы һәм әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы.

11. Тиешле карар кабул ителгән көннән соң бер көн эчендә кабул ителгән карар нәтиҗәләре турында хәбәрнамә язма рәвештә вәкаләтле орган тарафыннан юридик затка җибәрелә.

12. Субсидия бирү вәкаләтле орган һәм субсидия бирү турында карар кабул ителгән юридик зат (алга таба – субсидия алучы) арасында субсидия бирү турында килешү нигезендә гамәлгә ашырыла. Субсидия бирү турында килешү субсидия бирү турында билгеләнгән тәртиптә карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән ике көн эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы раслаган типик форма буенча төзелә.

Субсидия бирү турында килешүдә субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше, чаралар оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнар төрләре, субсидияне күчерү тәртибе, субсидияне куллану турында хисап тапшыру тәртибе һәм вакытлары, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияне агымдагы финанс елында кире кайтару очраклары һәм тәртибе, Министрлык һәм Финанс министрлыгы тарафыннан субсидия алучының аны бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүләр үткәрүгә субсидия алучының ризалыгы (устав (җыелма) капиталларында гавәми-хокукый оешмалар катнашында дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләр, хуҗалык иптәшлекләре һәм җәмгыятьләре, шулай ук устав (җыелма) капиталларында мондый иптәшлекләр һәм җәмгыятьләр катнашында коммерциячел оешмалардан тыш), субсидия алучының әлеге Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларын үтәве турында нигезләмәләр, субсидия акчасы исәбеннән чит ил валютасы сатып алуны тыю, югары технологияле чит ил

җиһазлары, чимал һәм комплектлау әйберләре сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясе валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән, шулай ук әлеге Тәртиптә билгеләнгән субсидия бирү максатларына ирешү белән бәйле бүтән операцияләрдән тыш, җаваплылык күздә тотыла.

13. Чара оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә субсидия күләме законнар нигезендә төзелгән һәм вәкаләтле орган белән килештерлгән чара оештыру һәм үткәрү чыгымнары сметасы нигезендә билгеләнә.

14. Чара оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны кайтаруга субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S = E * 100\ \%,$$

монда:

S – субсидия күләме, сум;

E – чара оештыру һәм үткәрүгә гамәлдә тотылган чыгымнар, сум.

15. Субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән 10 көн эчендә вәкаләтле орган субсидия алучыларның кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап счетларына субсидияләр күчерә.

16. Субсидия алучылар субсидияләр килү һәм аларны тоту буенча аерым бухгалтер исәбе алып бара.

17. Субсидия алучылар субсидия бирү турында килешүдә каралган тәртипкә, вакытларга һәм формага ярашлы рәвештә субсидияне куллану турында вәкаләтле органга хисап тапшыра.

18. Вәкаләтле органның тиешле таләбен алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән 30 көн эчендә субсидияләр субсидия алучылар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш:

вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы үткәргән тикшерүләр фактлары буенча билгеле булган субсидия алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар тапшырылган, субсидия алучы субсидия биргәндә билгеләнгән шартларны бозган очракта тулы күләмдә;

субсидияне куллану турында хисап бирелмәгән, хисап бирү вакытлары бозылган очракта тулы күләмдә;

субсидия акчасын максатчан файдаланмау билгеле булган очракта максатчан файдаланылмаган субсидия күләмендә.

19. Хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидия субсидия бирү турында килешүдә каралган очракларда хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр субсидия алучылар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

20. Субсидия алучылар әлеге Тәртипнең 18 һәм 19 пунктларында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару очракларын бозганда субсидияне кире кайтару вакыты узган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән җиде көн эчендә вәкаләтле орган әлеге акчаны законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару чараларын күрә.

21. Законнар нигезендә вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс

министрлыгы субсидия алучылар тарафыннан субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлүне тикшерүне гамәлгә ашыралар.

22. Субсидияләрне максатчан файдалануны тикшерүдә тотуны законнар нигезендә вәкаләтле орган гамәлгә ашыра.